**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 июль № 468

г. Казань

2016 – 2020 елларда Татарстан Республикасы мәгариф системасында стажировка һәм база мәйданчыклары эшен оештыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы турында» 2015 ел, 23 май, 497 нче карары белән расланган 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасын, «Мәгариф турында» 2013 ел, 22 июль, ТРЗ-68 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы турында» 2015 ел, 23 май, 497 нче карары белән расланган 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү» дигән 2.4 нче чарасы буенча «Гомуми белем бирүнең заманча механизмнарын һәм технологияләрен үстерү» бурычын тормышка ашыру өчен «Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирә торган дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә стажировка мәйданчыгы статусын бирергә.

2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы турында» 2015 ел, 23 май, 497 нче карары белән расланган 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү» дигән 2.4 нче чарасы буенча гомуми белем бирү системасында стажировка мәйданчыгы һәм база мәйданчыклары турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) расларга.

3. Билгеләнгән тәртиптә стажировка һәм база мәйданчыклары статусы бирелгән мәгариф оешмалары эшчәнлегенә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган субсидияләр һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру өчен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы» ведомствосы буенча күздә тотылган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы мәгариф системасында стажировка мәйданчыклары эшен оештыру турында» 2011 ел, 3 декабрь, 988 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәгариф системасында стажировка мәйданчыклары эшен оештыру турында» 2011 ел, 3 декабрь, 988 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 18 апрель, 265 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәгариф системасында стажировка мәйданчыклары эшен оештыру турында» 2011 ел, 3 декабрь, 988 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 15 ноябрь, 880 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәгариф системасында стажировка мәйданчыклары эшен оештыру турында» 2011 ел, 3 декабрь, 988 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 23 гыйнвар, 29 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәгариф системасында стажировка мәйданчыклары эшен оештыру турында» 2011 ел, 3 декабрь, 988 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 8 сентябрь, 654 нче.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 июль, 468 нче карары белән расланды

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы турында» 2015 ел, 23 май, 497 нче карары белән расланган 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү» дигән 2.4 нче чарасы буенча гомуми белем бирү системасында стажировка мәйданчыгы һәм база мәйданчыклары турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы турында» 2015 ел, 23 май, 497 нче карары белән расланган 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү» дигән 2.4 нче чарасы буенча «Гомуми белем бирүнең заманча механизмнарын һәм технологияләрен үстерү» бурычы кысаларында Татарстан Республикасының гомуми белем бирү системасында стажировка һәм база мәйданчыкларын оештыру шартларын һәм эшләү тәртибен билгели.

1.2. Стажировка һәм база мәйданчыклары үз эшчәнлекләрендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Стажировка мәйданчыгы – «Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирә торган дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең (алга таба – Институт) өстәмә һөнәри белем бирү буенча мәгариф программалары кысаларында стажировка рәвешендә гомуми белем бирү системасы хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү өчен мәгариф оешмасы базасында оештырылган структура.

База мәйданчыгы – базаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы турында» 2015 ел, 23 май, 497 нче карары белән расланган 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик

берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү» дигән 2.4 нче чарасы кысаларында стажировка (тулысынча яки өлешчә) рәвешендә мәгариф системасының педагог һәм җитәкче хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү буенча өстәмә һөнәри белем бирү программалары тормышка ашырыла торган гомуми белем бирү оешмасы, өстәмә һөнәри белем бирү оешмасы, һөнәри белем бирү оешмасы, югары белем бирә торган мәгариф оешмасы, коммерциячел булмаган оешма.

1.4. Стажировка мәйданчыгы статусы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән түбәндәгеләргә бирелә:

гомуми белем бирү системасында педагог һәм идарә кадрлары квалификациясен күтәрүне гамәлгә ашырырга хокукы булган мәгариф оешмасына;

белем бирү процессын оештырырга мөмкинлек бирә торган югары квалификацияле педагогик кадрлар, заманча укыту чаралары, җиһазлар белән тәэмин ителгән мәгариф оешмасына.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының һәм стажировка мәйданчыгының үзара хезмәттәшлеге Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Институт арасындагы Килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

База мәйданчыгы статусы мәгариф оешмасына база мәйданчыкларын конкурс нигезендә сайлап алу буенча бирелә. База мәйданчыкларын конкурс нигезендә сайлап алу Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә башкарыла, һәм ул түбәндәгеләрне раслый: нигезендә сайлап алу турында игълан, конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен заявка формасы, конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү хакында нигезләмә, конкурс материалларын бәяләү методикасы, эксперт бәяләмәсе формасы, республика конкурс комиссиясе составы, эксперт комиссиясе составы.

Республика комиссиясе беркетмәсе нигезендә конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләр игълан ителә.

1.5. Мәгариф оешмасына стажировка яки база мәйданчыгы статусын бирү мәгариф оешмасының оештыру-хокукый формасын, тибын һәм төрен үзгәртүгә китерми.

1.6. Стажировка мәйданчыгы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге өчен җаваплылылык Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында була, һәм ул Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгына кимендә елга бер тапкыр ирешкән нәтиҗәләр турында, шул исәптән 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының тиешле чараларын тормышка ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре хакында мәгълүматны үз эченә алган хисап кертә.

База мәйданчыклары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге өчен җаваплылык Институтта була, һәм ул Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына кимендә елга бер тапкыр ирешкән нәтиҗәләр турында, шул исәптән 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының тиешле чараларын тормышка ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре хакында мәгълүматны үз эченә алган хисап кертә.

## 2. Стажировка мәйданчыгы эшчәнлегенең максаты һәм бурычлары

2.1. Стажировка мәйданчыгы эшчәнлегенең максаты – гомуми белем бирү системасы хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүне һәм стажировкасын оештыру һәм тәэмин итү.

2.2. Стажировка мәйданчыгы 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының төп чараларын тормышка ашыру өчен гомуми белем бирү системасы педагогик һәм идарә кадрларының һөнәри компетенциясен формалаштырырга һәм үстерергә, гомуми белем бирү буенча федераль дәүләт мәгариф стандартларын кертергә, Татарстан Республикасының мәгариф оешмаларында инклюзив белем бирүне үстерергә мөмкинлек бирә.

2.3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы турында» 2015 ел, 23 май, 497 нче карары белән расланган 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү» дигән 2.4 нче чарасы буенча стажировка мәйданчыгы эшчәнлегенең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

гомуми белем бирү буенча федераль дәүләт мәгариф стандартларын тормышка ашыру өчен педагогик һәм идарә кадрларының квалификациясен өзлексез һәм нәтиҗәле күтәрү шартларын булдыру, беренче чиратта, төп гомуми белем бирү буенча төп мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы укытучыларның һөнәри компетенцияләре дәрәҗәсен күтәрү нигезендә;

квалификация күтәрү процессында аерым уку-укыту предметларының һәм предмет өлкәләренең (математика, тарих, җәмгыять белеме, география, технология, сәнгать, физик культура) укыту эчтәлеген һәм технологияләрен модернизацияләү концепцияләрен эшләү нигезендә гомуми белем бирү буенча федераль дәүләт мәгариф стандартларын кертү мәсьәләләре буенча мәгариф хезмәткәрләрен әзерләүне гамәлгә ашыру;

стажировка мәйданчыгы нигезендә аерым предметларны һәм предмет өлкәләрен (математика, тарих, җәмгыять белеме, география, технология, сәнгать, физик культура) модернизацияләү концепцияләрен эшләү һәм тормышка ашыруны квалификацияле тәэмин итү буенча ресурслар, фәнни-методик һәм консультация үзәген төзү, аларның фәнни-методик, мәгълүмати һәм кадрлар белән тәэмин ителешен булдыру, шулай ук тупланган уңай тәҗрибәне Татарстан Республикасында да, аннан читтә дә тарату;

мәгариф һәм фәнни оешмаларның инновацион методик челтәрләрен һәм консорциумнарын оештыруны стимуллаштыру, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалар белән эшне оештыру юлы белән инновацияләр тәҗрибәсен тарату.

3. Стажировка мәйданчыгының вазыйфалары һәм аның эшчәнлеген оештыру

3.1. Стажировка мәйданчыгының вазыйфалары булып түбәндәгеләр тора:

стажировка һәм база мәйданчыкларын матди-техник тәэмин итүгә техник йөкләмәне формалаштыруда катнашу;

база мәйданчыклары эшчәнлеген җайга сала торган документларны әзерләүне оештыру;

мәгариф программалары, уку-укыту-методик комплектлар, методик тәкъдимнамәләр эшләү, аларны тиражлауны һәм таратуны тәэмин итү;

база мәйданчыкларында үткәрелә торган чаралар программасын стажировка мәйданчыгы планы белән килештерү;

база мәйданчыклары җитәкчеләре белән инструктив-методик киңәшмәләр үткәрү;

база мәйданчыклары эшчәнлегенә фәнни һәм методик ярдәм күрсәтү;

мәгариф оешмалары – база мәйданчыклары хезмәткәрләре өчен семинарлар системасын оештыру;

план-график нигезендә тәкъдим ителгән чаралар кысаларында квалификация күтәрү һәм башка чаралар үткәрү;

база мәйданчыклары эшчәнлегенә мониторинг үткәрү һәм аның йомгакларын гомумиләштерү;

стажировка мәйданчыгы эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг үткәрү һәм мониторинг нәтиҗәләрен федераль операторларга һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгына кертергә.

3.2. Базасында стажировка мәйданчыгы төзелгән мәгариф учреждениесе җитәкчесе аның эшчәнлеген оештыра.

3.3. Стажировка мәйданчыгы җитәкчесе Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан билгеләнгән вакытларда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына башкарылган эш турында хисап кертә.

4. Стажировка һәм база мәйданчыклары эшчәнлеген финанслау

4.1. Стажировка һәм база мәйданчыклары эшчәнлеген финанслау федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган субсидияләр һәм «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру өчен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы» ведомствосы буенча күздә тотылган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4.2. Стажировка һәм база мәйданчыклары статусы бирелгән мәгариф оешмалары эшчәнлегенә бәйле чыгымнарны тәэмин итү өчен күздә тотылган федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы акча түбәндәгеләргә бүлеп бирелә:

стажировка һәм мәйданчыкларын матди-техник җиһазландыруга;

стажировка мәйданчыгы базасында белем бирүне тәэмин итүче белгечләрнең эш хакына һәм командировка чыгымнарына;

белем бирүне оештыруга, консультацияләр, тыңлаучылар әзерләү буенча көндезге һәм дистанцион чаралар (семинарлар, конференцияләр, эшлекле уеннар, видеоконференцияләр, форумнар, тренинглар һ.б.) үткәрүгә;

аның базасында педагогик хезмәткәр уку узачак мәгариф оешмасының өстәмә һөнәри белем бирү хезмәтләре өчен түләүгә;

чара тематикасы буенча педагогик һәм идарә кадрларының квалификациясен күтәрүне, аларны яңадан әзерләүне оештыру һәм стажировкаларын үткәрү, инклюзив белем бирүне кертеп;

проект-тикшеренү һәм күмәк метапредмет эшчәнлеге зонасын оештыру өчен база мәйданчыкларының мәктәп китапханәләрен җиһазландыру;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы турында» 2015 ел, 23 май, 497 нче карары белән расланган 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү» дигән 2.4 нче чарасын тормышка ашыру нәтиҗәлелегенә мониторинг үткәрү.

5. Стажировка һәм база мәйданчыклары эшчәнлеген туктату

5.1. Стажировка һәм база мәйданчыклары эшчәнлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы турында» 2015 ел, 23 май, 497 нче карары белән расланган 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү» дигән 2.4 нче чарасын тормышка ашыру вакыты тәмамланган очракта туктатыла.